**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2019 №384

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның 9 октябрендәге
570 номерлы «Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы территориясендә
шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары
җайга салынган тарифлар буенча автомобиль
транспортында даими рәвештә пассажирлар
һәм багаж йөртүгә бәйле чыгымнарның бер
өлешен каплау максатында, транспорт йөртүчеләргә
субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы
карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 19 апрелендәге 261 номерлы «2018-2020 елларда Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны маршрутларында җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне оештыру буенча чаралар планын ("юл картасын") раслау турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 9 октябрендәге «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында, транспорт йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» гы 570 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләр:

1.1. 5 нче абзацтагы 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шул ук вакытта пассажирлар ташучының Кереме 2019 елда - 0,4, 2020 елда - 0,5 һәм көненә ике әйләнештән дә ким булмаган автобусны тутыру коэффициентын куллануны исәпкә алып исәпләнә.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында:/ www. spassriy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (///http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән срокта бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н. А Казаковага йөкләргә

Татартстан Республикасы
Спас муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе В.А.Осокин